| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«28» февраля 2023г. № 36

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 апрелендәге 184 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Административ комиссиясен төзү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 апрелендәге 184 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Административ комиссиясен төзү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районының административ комиссиясе составында Г.Р. Садыйкова вазыйфасының атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге баш белгече;»;

Б) күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының административ комиссиясе эше регламентына:

1) 1.1 пунктта «оештыру» сүзен «төзү» сүзенә алмаштырырга;

2) 1.3 пунктта «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 1.5 пунктта «оештыру» сүзен «төзү» сүзенә алмаштырырга;

4) 2.10 пунктның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Административ комиссия әгъзалары килүчеләрне кабул итә.»;

5) 3.1 пунктта «оештыру» сүзен «төзү» сүзенә алмаштырырга;

6) 5.5 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин